ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2014 Казан ш. № 6-87/тп

***"Газпром трансгаз Казан" ҖЧҖнең газ бүлү челтәрләренә газ куллану җиһазларын технологик тоташтыруга түләүне 2015 елга билгеләү турында***

"Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы" 31.03.1999 ел № 69-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе территориясендә газ бәяләрен, аны транспортлау хезмәтләренә тарифларны һәм газ бүлү челтәрләренә газ куллану җиһазларын технологик тоташтыру өчен түләүне дәүләти көйләү турындагы" 29.31.2000 ел № 1021 карарына, Тарифлар буенча федераль службаның "Җылылык бирүче оешмалар бирә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифларның Россия Федерациясе субъектлары буенча уртача соң чик максималь кимәлләрен билгеләү турындагы" 11.10.2014 ел № 227-э/3 боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. "Газпром трансгаз Казан" ҖЧҖнең газ бүлү челтәрләренә газ куллану җиһазларын технологик тоташтыруга түләүне шушы карарның кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү 2015 елның 1 гыйнвареннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар аны рәсми игълан иткән көннән ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.12.2014 № 6-87/тп
карарына кушымта

## “Газпром трансгаз Казан” ҖЧҖнең газ бүлү челтәрләренә газ куллану җиһазларын технологик тоташтыруга 2015 елда түләү

| Т. № | Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеге чикләреннән газ бүлү челтәрләренә кадәр ара | Технологик тоташу өчен түләү, сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | НДСны исәпләмичә | НДСны исәпләп <*> |
| 1. | Максималь газ чыгымы сәгатькә 5 кубометрдан артмаган, мөрәҗәгать итүченең шушы ноктада тоташкан газ куллану җиһазларының газ чыгымын исәпкә алып (газны эшмәкәрлек (коммерция) максатларында кулланырга ният итмәгән башка мөрәҗәгать итүчеләр өчен), газ куллану җиһазларыннан мөрәҗәгать ителгән газ бүлүче оешманың проекттагы эш басымы 0,3 МПа.дән зуррак булмаган газ бүлү челтәренә кадәр туры линия буенча үлчәнгән ара 200 метрдан ары булмаган һәм чаралар үзләре газны редукцияләү пунктлары кормыйча, кертү газүткәргечләре төзүне генә күздә тоткан очракта | 10 м.га кадәр (аны да кертеп) | 16 949,16 | 20 000,00 |
| | | 10 м.дан 20 м.га кадәр (аны да кертеп) | 25 423,73 | 30 000,00 |
| | | 20 м.дан ары | 42 372,89 | 50 000,00 |
| 2. | Максималь газ чыгымы сәгатькә 15 кубометрдан артмаган, мөрәҗәгать итүченең шушы ноктада тоташкан газ куллану җиһазларының газ чыгымын исәпкә алып (газны эшмәкәрлек (коммерция) максатларында кулланырга ният итмәгән башка мөрәҗәгать итүчеләр өчен), газ куллану җиһазларыннан мөрәҗәгать ителгән газ бүлүче оешманың проекттагы эш басымы 0,3 МПа.дән зуррак булмаган газ бүлү челтәренә кадәр туры линия буенча үлчәнгән ара 200 метрдан ары булмаган һәм чаралар үзләре газны редукцияләү пунктлары кормыйча, кертү газүткәргечләре төзүне генә күздә тоткан очракта | 200 м.га кадәр (аны да кертеп) | 42 372,89 | 50 000,00 |

<*> Мөрәҗәгать итүче физик зат булган очраклар өчен

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге